ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.12.2024 с.Старое Дрожжаное № 494

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә эвакуацияләнгән халыкны вакытлыча урнаштыру пунктларын булдыру һәм эшен оештыру турындагы карарга үзгәрешләр кертү хакында

Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 2024 елның 12 сентябрендәге М-11-3271 номерлы хаты нигезендә, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр янаганда яисә барлыкка килгәндә Чүпрәле муниципаль районы халкын вакытлыча күчерү (урнаштыру) буенча чараларны планлаштыру, тәэмин итү һәм үткәрү буенча бурычларны хәл итү максатларында, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә эвакуацияләнгән халыкны вакытлыча урнаштыру пунктларын булдыру һәм эшен оештыру турында» Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 14 декабрендәге 528 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә һәм карар текстында «вакытлыча урнаштыру пункты (ВУП)» сүзләрен «вакытлыча урнаштыру һәм тукландыру пункты» сүзләренә алмаштырырга;

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәл килеп туганда эвакуацияләнгән халыкны вакытлыча урнаштыру пункты турында нигезләмәдә «вакытлыча урнаштыру пункты (ВУП)» сүзләрен «вакытлыча урнаштыру һәм тукландыру пункты» сүзләренә алмаштырырга;

2 нче һәм 3 нче кушымталарда «вакытлыча урнаштыру пункты (ВУП)» сүзләрен «вакытлыча урнаштыру һәм тукландыру пункты» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының кабул итү эвакуация комиссиясе рәисе А.Ф. Заляловка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов